**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**27.09.2021** г.Казань **№ 123од**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2015 елның 11 мартындагы 01-02/170 номерлы боерыгы белән расланган исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында биләүләре коррупция куркынычы белән бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2015 елның 11 мартындагы 01-02/170 номерлы боерыгы белән расланган исемлегенә (2015 елның 22 декабрендәге 01-02/821 номерлы, 2016 елның

5 октябрендәге 01-02/265 номерлы, 2018 елның 9 гыйнварындагы 1 од номерлы, 2018 елның 23 августындагы 91 одномерлы, 2020 елның 4 декабрендәге 146од номерлы боерыклар белән керетлгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 һәм 5 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.Вазыйфаларның әйдәүче төркеменең «җитәкчеләр» категориясенең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

финанс бүлеге башлыгы урынбасары;

кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгы урынбасары;

хокукый экспертиза һәм нормалар иҗат итү бүлеге башлыгы урынбасары;

норматив хокукый актларны теркәү һәм Министрлык эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы урынбасары;

түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлеге башлыгы урынбасары;

җирле үзидарә һәм муниципаль регистр алып бару өлкәсендә норматив хокукый эш бүлеге башлыгы урынбасары;

хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге башлыгы урынбасары;

җәмәгать судьялары эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы урынбасары;

норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җирле үзидарә һәм муниципаль регистр алып бару өлкәсендә норматив хокукый эш бүлегенең муниципаль регистрына кертү бүлекчәсе мөдире.

балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү бүлекчәсе мөдире.

5. Вазыйфаларның әйдәүче төркеменең «белгечләр» категориясенең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

җирле үзидарә өлкәсендә территориаль оештыру һәм тикшереп тору мәсьәләләре бүлегенең әйдәп баручы советнигы;

җирле үзидарә органнарына хокукый консультацион-методик ярдәм бүлегенең әйдәп баручы советнигы;

кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлегенең аның вазыйфасына түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын каплау турында адвокатлар тәкъдим иткән реестрларның тулылыгын һәм нигезлелеген тикшерүне гамәлгә ашыру керә торган әйдәп баручы консультанты;

җирле үзидарә һәм муниципаль регистр алып бару өлкәсендә норматив хокукый эш бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлегенең әйдәп баручы белгеч-эксперты.».

Министр Р.И. Заһидуллин